| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО УПРАВЛЕНИЯ, ИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.09.2021 Казан № п/254

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачуны (акча салуны) һәм булдыруны, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктының «и» пунктчасы, «Коррупциягә каршы торуның кайбер мәсьәләләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Указының 2 пункты һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен вазыйфа биләгәндә Россия Федерациясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 8 июнендәге ПУ-542 номерлы Татарстан Республикасы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт

граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) расларга.

2. Хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2021 елның 28 сентябрендәге п/254 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

Министрның беренче урынбасары.
Министр урынбасары, 2 штат берәмлеге.
Режимлы эш һәм махсус элемтә белгече (әйдәп баручы белгеч).